# “Рифкат чишмәсен” төзекләндерү

2023 елның октябрендә авылдашларыбыз данлыклы якташыбыз, табиб-профессор Таҗиев Рифкат Минһаҗ улы хөрмәтенә “Рифкат чишмәсе” дип исемләнгән чишмәдә төзекләндерү эшләре алып бардылар. Бу изге эшне Минегали Гайнетдинов җитәкчелегендә оныгы белән, Таҗиевлар Рифнур, Рамил, Илнур, шулай ук Нәҗметдинов Рәвил, Минегулов Фәрит, Шакиров Рафаэль, Тәкәштән Тимеркәев Рифкат абыйның улы Рунар һәм Гильфанов Рамил башкардылар. Аларның барысына да авыл халкы, күрше авыл кешеләре исеменнән бик зур рәхмәтләрне җиткерәбез! Изге гамәлләрегез үзегезгә йөз булып кайтсын, мәрхәмәтле авылдашларыбыз!

Авылдашларыбыз алга таба да бу чишмәнең шифалы суларыннан сихәт ала алырлар, алла боерса!








Түбәндәге фотоларда күрсәтелгән җиһазларны Минегали Гайнетдинов алдагы көз-кыш айларында реставрацияләп, яз башында “Рифкат чишмәсенә” уранштырырга планлаштыра.






VANS

